КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 сентябрь г.Казань № 844

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 387 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 37 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибендә:

1.3 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәдәни мирас объектлары – тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә барлыкка килгән, тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгать, фән һәм техника, эстетика, этнология яки антропология, социаль мәдәният күзлегеннән кыйммәтле байлык булып торган, эпохаларны һәм цивилизацияләрне таныклаган, культураның барлыкка килүе һәм үсеше турындагы мәгълүматларның төп чыганаклары булып торган территорияләр, рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре, фән һәм техника объектлары һәм матди культураның башка предметлары белән

тарихи бәйләнеше булган күчемсез мөлкәт объектлары (археология мирасы объектларын кертеп) һәм башка объектлар;»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Вәкаләтле орган, халык белән чара үткәрү турындагы хәбәрнамәне алганнан соң, аны теркәгән көндә, хәбәрнамә 16 сәгать 00 минуттан соң кергән очракта, киләсе эш көненең беренче яртысында хәбәрнамәнең күчермәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына җибәрә, ул Татарстан Республикасындагы Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрен) саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтле махсус компетенциядәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты бу Тәртипнең 2.2 нче пункты нигезендә хәбәрнамәне алган көннән бер эш көне эчендә вәкаләтле органга әлеге чараны үткәрү мөмкинлеге булу яки булмау турындагы нигезләнгән бәяләмә белән рәсми җавап җибәрә.»;

3.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Вәкаләтле орган, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү мөмкинлеге булмау турында бәяләмә алганнан соң, бер эш көне эчендә халык белән чара оештыручыга халык белән чара үткәрү урынын һәм (яки) вакытын үзгәртү турында нигезләнгән тәкъдим җибәрә.»;

3.4 нче пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин